ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫАЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 10.03.2026 361/1 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районында гражданнар оборонасы штабын төзү турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 1535 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 19 гыйнварындагы 7 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 21 ноябрендәге 1535 номерлы карары белән расланган Алабуга муниципаль районында гражданнар оборонасы штабын төзү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 20 февралендәге 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы нигезендә, Алабуга муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы белән идарә итүне оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты».

1.3. Нигезләмәнең 1 бүлегенең 8 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек муниципаль район территориясендә мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган хәвефләрдән халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклауга әзерлек чараларын алдан күрүдән гыйбарәт.».

2. Әлеге карар рәсми төстә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 2AE1AA8E107BD0A6911BA308E44A8D0A
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 28.01.2025 до 23.04.2026

Э.Р. Әхмәдиева

Лист согласования к документу № 361/1 от 10.03.2026
Инициатор согласования: Половинкина И.А. Главный специалист
Согласование инициировано: 12.03.2026 14:54

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 12.03.2026 - 15:24 | - |